ГЛАВА АЗАЛАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2024 ел , 20 нче март

№ 3

2023 елның 10 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы гражданнары халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы гражданнарының халык җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-РТЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. "2023 елның 10 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына үзгәреш кертү турында" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы гражданнары халык җыенын Юлтимер авылы мәдәният йорты бинасында, Юлтимер авылы Елга урамы, 5 йорты адресы буенча, 2024 елның 30 мартына 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2023 елның 10 ноябрендәге Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Юлтимер авылы гражданнарының халык җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" һәм "2024 елда Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлегенең Юлтимер авылында гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

1. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Юлтимер торак пунктында урамнарнарын яктырту объектларын карап тоту һәм яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
2.Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту (Юлтимер торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); Юлтимер авылында Яңа, Яшьләр,Үзәк,Тау урамнары буенча юлларны ремонтлау (таш ташу һәм вак таш җәю, юл өслеген тигезләү, махсус техника арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Юлтимер торак пунктында җәй көне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка, ГАЗ-САЗ-3512 автомашинасы, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы, ГАЗ-САЗ-3512 автомашинасы өчен запас частьләр сатып алу);
4. Янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау (сулыкны төзекләндерү (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
5. Традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Юлтимер авылы зираты территориясен киңәйтү, төзелеш материаллары сатып алу һәм койма кую өчен түләү);
6. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары булмаган (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында һәләк булганнар исемлегенә төзәтмәләр кертү һәм яңарту);

7. Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Юлтимер авылы торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп чар җыелу урыннарын чистарту (махсус техника арендалау, килешү буенча эшләр өчен түләү)?;

“ӘЙЕ” “ЮК?”

3. Әлеге карарны 7 көн эчендә Азалак авылы территориясендә урнашкан махсус мәгүлүмәти стентларда урнаштырырга, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, https://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

РТ Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы; И.Г.Габдулгазизов

3